Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Колшәрип авыл Советы

КАРАР

24 июнь 2025 ел № 109

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Колшәрип авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә,

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында аны кабул иткән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Колшәрип авыл җирлеге
башлыгы А.Ф. Кәшәфетдинов